СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 5-36 от «14» ноября 2019 г.

Мамадыш муниципаль районында милли һәм региональ проектларны гамәлгә ашыруның барышы турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең 2024 елга кадәр милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М. Р. Хуҗаҗановның Мамадыш муниципаль районында милли һәм региональ проектларны тормышка ашыруның барышы турындагы мәгълүматын тыңлаганнан соң, Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Р. Хуҗаҗановның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына, Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, Мамадыш муниципаль районы территориясендәге барлык милек рәвешләрендәге субъектларга, муниципаль район икътисадының һәм социаль сфераның өстенлекле тармакларына кагылышлы милли проектларны үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, милли проектларның максатчан күрсәткечләрен үтәү эшен активлаштырырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://mamadysh.tatarstan.ru. веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе

А.П.Иванов

000109